**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы**
**Татар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче**
**Татар Чаллысы авылында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**КАРАР**

24.11. 2023 ел № 6

2024 елга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылы гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авылы җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, билгеләргә
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә

**Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:**
- Урам яктырткычларын урнаштыру
- Агачларны кисү;
- кече архитектура формаларын һәм балалар спорт җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру,
- Материалны монтажлау һәм сатып алу ("Чаллы" елгасына металл баскыч ясау өчен)

Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
Суга батыру насосын сатып алу,

**Юл эшчәнлеге:**
җәйге һәм кышкы чорда юлларны карап тоту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.